ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«03 » марта 2021 ел № 51-р

Вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс игълан итү турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 23 гыйнварындагы 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турындагы нигезләмә нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Спорт мәктәбе» МБУ җитәкчесенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә

2. Конкурска документларны 2021 елның 6 мартында 8.00 сәгатьтән 2021 елның 26 мартында 16.00 сәгатькә кадәр Әгерҗе шәһәре, Гагарин урамы 13, 2 нче кабинет адресы буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында шимбә-якшәмбедән кала көн саен кабул итәргә, тел. 2-31-00.

3. Кушымта итеп бирелгән конкурс комиссиясенең составын расларга.

4. Конкурс комиссиясенә 2021 елның 29 мартында вакантлы вазыйфаны биләүгә кандидатларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрергә.

5. Әлеге күрсәтмәне Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм вакытлы матбугат басмасында - «Әгерҗе хәбәрләре» район газетасында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
03.03.2021 № 51-р
номерлы күрсәтмәсе белән расланган

**Конкурс комиссиясе составы**

1. Акбашев А.Э. -Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе;

2. Закирова Р.Ә. - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе (килешү буенча), комиссия рәисе урынбасары;

**Комиссия әгъзалары**:

1. Хәкимова Н.М.-Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетынын кадрлар бүлеге башлыгы, комиссия секретаре;
2. Фәтхетдинова Л.Г. - Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы;
3. Иманова Л.С. - Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының спорт һәм туризм бүлеге башлыгы;

4. Мурзин С.Е. - Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Әгерҗе районындагы җәмәгать ярдәмчесе (килештерү буенча);

5. Абзалиева Д.З. - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгы каршындагы дини һәм иҗтимагый оешмалар Советы әгъзасы, «Татмедиа» ААҖ филиалы «Әгерҗе хәбәрләре» газетасы мөхәррире (килештерү буенча);